ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЕМЕЛЬКИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**КАРАР**

№114 07.04.2020 ел

Емелькино авыл җирлеге Советының 22.02.2019 елның кабул ителгән 88 номерлы "Аксубай муниципаль районы Емелькино авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәне кабул итү хакында" карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 02.03.2007 елның 25-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасының муниципаль хезмәт турындагы 25.06.2013 елның 50-ТРЗ номерлы Кодексы, Емелькино авыл җирлеге Уставы нигезендә, Емелькино авыл җирлеге Советы карар итте:

1. 16 статьясындагы 2 пунктны "Муниципаль хезмәт белән бәйле тыюлар" түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

а) түбәндәге очраклардан тыш, коммерция яки коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашырга:

б) сәяси партия, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлау органы, съездда (конференциядә) яки башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез мөлкәт милекчеләр ширкәтенең гомуми җыелышында идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу;

в) Россия Федерациясе субъекты законында билгеләнгән тәртиптә яллаучы вәкиленең рөхсәте белән, түләүсез нигездә, (сәяси партия, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлау органы, съездда (конференциядә) яки башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез мөлкәт милекчеләр ширкәтенең гомуми җыелышында катнашудан тыш) коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашу;

г) Россия Федерациясе субъектының муниципаль берәмлекләре советында, башка муниципаль берәмлекләрнең берләшмәләрендә, шулай ук аларның идарә органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә тәкъдим итү;

д) муниципаль берәмлек (муниципаль берәмлек исеменнән оешманы гамәлгә куючы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен яисә муниципаль милектә булган акцияләр (устав капиталындагы өлешләр) белән идарә итү тәртибен билгели торган муниципаль хокукый актлар нигезендә) гамәлгә куючы (акционер, катнашучы) булган оешманың идарә органнарында һәм ревизия комиссиясендә муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә тәкъдим итү;

е) федераль законнарда каралган башка очраклар;

ж) эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шәхсән яки ышанычлы затлар аша шөгыльләнергә.

2. Әлеге карарны Емелькино авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Аксубай муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://aksubayevo.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмат телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Совет рәисе, Емелькино
авыл җирлеге башлыгы
Аксубай муниципаль районы                                        Н.И.Михайлова

СОВЕТ ЕМЕЛЬКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ